**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4672**
**02.06.2023**

Башкарма комитетның 2010 елның 26 гыйнварындагы 295 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алучыларга урнаштыру өчен рөхсәт бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2010 елның 26 гыйнварындагы 295 номерлы карары (Башкарма комитетның 2010 елның 10 февралендәге 763 номерлы, 2018 елның 25 апрелендәге 2306 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алучыларга урнаштыру өчен рөхсәт бирү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 пунктта 3, 4 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) яшәү урыны буенча теркәлү исәбе турында мәгълүматлар (гариза бирүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы);

4) торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслаучы мәгълүматлар (гариза бирүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы);»;

2) 20 пунктта 5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) яшәү урыны буенча теркәлү исәбе турында мәгълүматлар (гариза бирүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы).»;

3) 27 пунктта 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) яшәү урыны буенча теркәлү исәбе турында мәгълүматлар (гариза бирүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы).».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов